ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 17 феврале №3

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген раслау

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләтара һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтләр исемлеген актуальләштерүгә бәйле рәвештә, Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеген яңа редакциядә расларга (кушымта).
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында»гы 2013 елның 21 июнендәге 6 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы М.Г. Гатиятуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Олы Ачасыр авыл жирлеге башкарма
комитетының
2020 елның 17 февралендәге
3 нче карарына кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы
«Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан
күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр Исемлеге

| | *Муниципаль хезмәтләр* |
|---|---|
| 1. | Присвоение, изменение и аннулирование адресов |
| 2. | Агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү |
| 3. | Документлар күчермәләрен таныклау һәм алардан күчермәләр бирү |
| 4. | Нотариаль гамәлләр кылу: ышанычнамәне таныклау |
| 5. | Белешмәләр бирү (күчермәләр) |